**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

**Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**28 ноябрь, 2023 ел** **№ 1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 20 ноябрендә 15 сәгатьтә, 21 ноябрендә 11 сәгатьтә, 22 ноябрендә 15 сәгатьтә, 23 ноябрендә 14 сәгатьтә, 28 ноябрендә 16 сәгатьтә булган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән «2024 елда Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлеге Олы Подберезье торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның гаиләләренең балигъ булган әгъзаларыннан тыш даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәл әләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?" соравы буенча гражданнар җыенының беркетмәсе төзелде:

- янгын автомашинасын, җиһазларын, биналарын һәм ДЕПО эшчесенең тоту;
- авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту;
- җирлек торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын карап тору;
- территорияне торак пунктның Олы Подберезье санкцияләнмәгән чүплекләреннән чистарту;
- зират территориясен карап тору, төзекләндерү һәм ремонтлау, материаллар сатып алу;
- су үткәрү челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу.

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт итәргә.

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыенының нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 399 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 226, бу 56,6 % тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

«Риза» позициясе өчен гражданнар җыенында 222 катнашучы тавыш бирде; «Каршы» позициясе өчен җыенның 4 катнашучысы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены түбәндәгеләрне хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлегенең Олы Подберезье торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларның балигъ булган гаилә әгъзаларыннан тыш, 2024 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне башкару өчен юлларга:

- янгын автомашинасын, җиһазларын, биналарын һәм ДЕПО эшчесенең тоту;
- авыл җирлеге торак пункты территориясен карап тоту;
- җирлек торак пункты чикләрендә автомобиль юлларын карап тору;
- территорияне торак пунктның Олы Подберезье санкцияләнмәгән чүплекләреннән чистарту;
- зират территориясен карап тору, төзекләндерү һәм ремонтлау, материаллар сатып алу;
- су үткәрү челтәрләрен ремонтлау, материаллар сатып алу.

Экономия барлыкка килгән очракта, акчаны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Олы Подберезье авыл җирлеге Башкарма комитетына җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә рөхсәт итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Олы Подберезье авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында һәм рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка таратырга.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен юлларга.

Гражданнар җыенында рәислек иткән,
Олы Подберезье авыл җирлеге Башлыгы О.М.Емельянова